**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55**

**2023 елның 23 октябре** **98-РС номер**

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмә хакында» 2022 елның 05 декабрендәге 95-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2022 елның 21 декабрендәге 448-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022елның 28 декабрендәге 562-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның4 августындагы 416-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, Лаеш муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмә хакында» 2022 елның 05 декабрендәге 95-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына(кушымта нигезендә) өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарныИнтернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - муниципаль район Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

*Татарстан Республикасы*
*Лаеш муниципаль районы Советының*
*2023 елның 23 октябрендәге 98-РС*
*номерлы карарына кушымта*

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмә хакында»2022 елның 05 декабрендәге 95-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1.

2. 11 статьяда:

13 пунктның 1 Абзацында «шәраб материаллары,» сүзләреннән соң « составында шикәр булган эчемлекләр,» сүзләрен өстәргә;

13 унктның 5 пунктчасының 5 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. 12 статьяның 3 абзацында «һәм күрсәтелгән карар белән расланган чыгымнарның гомуми күләменең 3 процентыннан артыграк була алмый» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.14 статьяның 1 пунктындагы 1 пунктчасында «, шул исәптән шәһәр округы булган инфраструктураны бергәләп үстерү өчен муниципальара хезмәттәшлек турында килешүләр» сүзләрен өстәргә;

4.25.1 статьяның 1 пунктында «һәм аларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

5. 26 статьяның 2 пунктында «программаны раслаган башкарма комитет карары нигезендә бюджет чыгымнарының һәр максатчан маддәсе буенча.» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъектының югары башкарма органы, муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе билгеләгән дәүләт (муниципаль) программалары исемлеге һәм структурасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.»;

6. 28 статьяның 2 абзацына түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар өстәргә:
җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау исәбенә җирле бюджетларның керемнәрен түләүдән;
авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасының хәрәкәт итү кагыйдәләрен бозган өчен җирле бюджетларның керемнәре.

7. 38 статьяда:

3 пунктта «бюджет йөкләмәләре» сүзләреннән соң «һәм элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә үзгәрешләр кертә» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта «казначылык түләүләрен башкару турында (алга таба - боерык)» сүзләрен төшереп калдырырга..